# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге составына керүче Дүсмәт торак пунктында үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«30» октябрь, 2024 ел

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Дүсмәт торак пунктында 2024 елның «30» октябрендә узган үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Дүсмәт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 елда 500 сум күләмендә үзарасалым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-торак пункт территориясен төзекләндерү (Дүсмәт торак пункты территориясендә коры агачларны, куакларны кисү (эшләр өчен килешү буенча түләү));

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Дүсмәт торак пунктындагы юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту);

-Дүсмәт торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (урамнарны яктырту обьектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урамнарны яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру)) ремонтлау:

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 179 кеше кертелгән;
гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 118 кеше, 65,9 % тәшкил итә:
Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен -118 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ»позициясе өчен -0 граждан тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Дүсмәт торак пунктында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип таныргa.

2. Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлегенең Дүсмәт торак пунктында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип таныргa: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге Дүсмәт торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 елда 500 сум күләмендә үзарасалым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-торак пункт территориясен төзекләндерү (Дүсмәт торак пункты территориясендә коры агачларны, куакларны кисү (эшләр өчен килешү буенча түләү));

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Дүсмәт торак пунктындагы юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту);

-Дүсмәт торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (урамнарны яктырту обьектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урамнарны яктырту лампаларын сатып алу һәм алыштыру)) ремонтлау.

3. Әлеге карарны Дүсмәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Дүсмәт авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Дүсмәт авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе: Р.М.Ефимов